КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 15 ноябрь г.Казань № 879

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Амбулаториядә дәвалау вакытында дару чаралары һәм медицина әйберләре табиб рецептлары буенча түләүсез җибәрелә торган авырулар категорияләре исемлеген раслау турында» 2005 ел, 17 гыйнвар, 4 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Амбулаториядә дәвалау вакытында дару чаралары һәм медицина әйберләре табиб рецептлары буенча түләүсез җибәрелә торган авырулар категорияләре исемлеген раслау турында» 2005 ел, 17 гыйнвар, 4 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 28 апрель, 343 нче; 2009 ел, 16 март, 149 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле пунктлар өстәргә:

«1.1. Татарстан Республикасының медицина оешмаларына дару чаралары белән түләүсез тәэмин итәргә хокуклы гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турындагы мәгълүматны Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы аша Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә һәм Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы операторы тарафыннан билгеләнгән форматларда бирүне тәэмин итәргә.

1.2. Дару чаралары белән түләүсез тәэмин итәргә хокуклы гражданнарга социаль яклау (ярдәм) чаралары күрсәтү турындагы мәгълүмат Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла. Әлеге мәгълүматны Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыру (аннан

алу) «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 ел, 17 июль, ФЗ-178 нче Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

1.3. Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланучылар бу карарның 1.1 нче пунктында күрсәтелгән мәгълүмат белән тәэмин итүчеләр, шулай ук гражданнар булып тора. Гражданнарның мәгълүмат системасыннан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша гамәлгә ашырыла.».

2. Бу карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\879.docx